ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОСПАССКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молождежная, д. 13, с. Новоспасск, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Молодежная урамы, 13 нче йорт,
Яңа Спас авылы, Зәй районы, 423535
ИНН/КПП: 1647011467/164701001

Телефон, факс 64-5-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru, сайт: ww.zainsk.tatarstan.ru/rus/novospasskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«21» января 2023 г.** **№3**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 24 маендагы 8 номерлы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 24 маендагы 8 номерлы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 13 декабрендәге 24 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 13 номерлы, 2020 елның 12 ноябрендәге 18 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 14 пунктны өстәргә:

«14) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак

пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
житәкчесе Танчук Н.В.